ГАЛИМҖАН ГЫЙЛЬМАНОВ

# ФИЛ ТӨШКӘ СЫЙМЫЙ



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

## МИН – ЧЫН ТАТАР МАЛАЕ

Әйдәгез, танышыйк:
Галимҗан – исемем.
Рас килә, ди әти,
Исемгә җисемем.

Чатнатып сөйләшәм
Үз ана телемдә.
Оялмыйм, курыкмыйм, –
Мин бит үз илемдә!

Үземне Ватанны
Сакларга әзерлим;
Дөресен әйткәндә,
Күптәннән әзер мин!

Башымда – чигүле,
Каюлы түбәтәй.
Догалар укырга
Өйрәтә дәү әти.

Әйткәнне көтмичә,
Әнигә булышам.
Яшермим, аз гына
Абыйдан калышам...

Тәүфыйклы булырга
Кирәген беләм мин.
Чын татар малае
Йөрәгем белән мин!





## НӘСЕЛ АГАЧЫ

Бабам әйтә: «Һәрбер нәсел
Бер мәгърур имән кебек.
Якын ул, газиз, кадерле,
Атаң йә инәң кебек.

Ботаклары бихисап күп, —
Бар туганнарың шулдыр.
Шушы нәсел агачында
Син яфрагыңны булдыр!

Бу агачка җылы яңгыр,
Шифалы нурлар кирәк.
Иң мөһиме, бу агачка
Ныклы тамырлар кирәк!

Дөнья синең нәселеңне
Шул тамырлардан таныр.
Иң үзәктә, иң тирәндә
«Татар» дигән җан тамыр».

Бабам әйтә: «Һәрбер нәсел
Үз агачын үстерә.

Нәсел ныклы булган саен,
Илгә күбрәк көч керә!»



## ТАТАР КОШЫ

Бакчабызга бер кош килде,
Куш каенны сайлады ул.
Күңелләрне моңландырып,
Өзеп-өзеп сайрады ул...

Бу кадәр моңлы булмаса,
Каенга да кунмас иде.
Әгәр... Әгәр кош булмаса,
Ул моңлы да булмас иде...

Нигә шулай сайрый соң ул,
Канат җәеп куш каенга?
Нинди сагыш төште икән
Кеп-кечкенә башкаена?

Кош кына шул... Кеше булса,
Кайтыр иле булыр иде.
Әгәр сөйләр теле булса,
Татар теле булыр иде!..